**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**«Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» федераль проекты чараларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» федераль проекты чараларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» 2017 елның 29 маендагы ПУ-448 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2021 елның 11 августындагы ПУ-635 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең2023 елның 3 апрелендәге 196 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган «Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» федераль проекты чараларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Р.Р. Гайзатуллинны, Р.Ш. Ганибаевны, А.Р. Медведевны, Д.С. Романовны, А.М. Фроловны, А.В. Шадриковны чыгарырга;

б) Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Җиһаншин Азат Илдус улын – Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрын;

Кадыйров Марат Рафаэль улын – «Бөтенроссия инвалидлар җәмгыяте» гомумроссия иҗтимагый оешмасының «Татарстан Республикасы инвалидлар җәмгыяте» Татарстан республика оешмасы» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе әгъзасын (килешү буенча);

Миронова Кристина Андреевнаны – «РОССИЯ ӨЧЕН» ХАЛЫК ФРОНТЫ» гомумроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан Республикасындагы төбәк бүлекчәсе төбәк башкарма комитетының эксперт-проект эше буенча координаторын (килешү буенча);

Фәйзрахманов Марат Җәүдәт улын – Татарстан Республикасы финанс министрын;

Шәйдуллин Дамир Фәрит улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасарын;

в) Комиссия әгъзасы Н.М. Зиннәтуллинаның фамилиясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Нагуманова».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 10 март
№ 189